Татарстан Республикасы Хисап Палатасы



# 2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында ХИСАП









Казан-2013 ел

Эчтәлек

Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре ........ 3
Тикшерү- ревизия эшчәнлеге ........ 5
Экспертиза – аналитика эшчәнлеге ........ 25
Коррупциягә каршы тору буенча эшчәнлек ........ 33
Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү ........ 37
Муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү ........ 40
Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек итү ........ 42
Эшчәнлектә хәбәрдарлык ........ 44

# 2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эше турында хисап «Татарстан Республики Хисап палатасы турындагы» Законның 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта закон тарафыннан билгеләнгән максат һәм вәкаләтләрне башкару буенча Хисап палатасының 2012 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

## Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан дәүләт финанс тикшерүе органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру бурычы куелды. Моңа бәйле рәвештә тикшерү чаралары барышында Хисап палатасы бюджет чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү, конкрет тәкъдим һәм киңәшләр әзерләүгә аерым игътибар бирә. Ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча чаралар күрү даими тикшерелеп тора.

2012 елда Хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомумән алганда **3 043 991,9 мең сум күләмендә бозулар ачыкланды**, барлыгы **2 530 004,3 мең сумлык** чара барлык дәрәҗә бюджетларга **кире кайтарылды** һәм ачыкланган бозулар буенча **чаралар күрелде** (ачыкланган бозуларга карата 83,1%).

Ачыкланган бозулар турында мәгълүмат һәм барлык тикшерү чаралары материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәсе буенча 104 вазыйфаи зат **дисциплинар җаваплылыкка тартылды**, 15 кеше **эш урыныннан азат ителде**. **3 юридик, 10 вазыйфаи зат** штраф формасында **административ җаваплылыкка тартылды**. Нәтиҗәләр буенча **4 җинаять эше** кузгатылды.

Хисап палатасының эшенең төп күрсәткечләре таблицада бирелде.

| Эш күрсәткече | 2009 ел | 2010 ел | 2011 ел | 2012 ел |
|---|---|---|---|---|
| **I. Тикшерү-ревизия эшчәнлеге** | | | | |
| Үткәрелгән тикшерү-ревизия чаралары саны | 48 | 51 | 50 | 53 |
| Тикшерү-ревизия чаралары үткәргәндә тартылган объектлар саны (берәмлек) | 464 | 470 | 481 | 483 |
| Бозуларның ачыкланган күләме (мең сумнарда) | 2 201 772,8 | 2 984 585,9 | 3 035 829,8 | 3 043 991,9 |
| **II. Экспертиза-аналитика эшчәнлеге** | | | | |
| Үткәрелгән экспертиза- аналитик чараларның гомуми күләме | 100 | 104 | 112 | 108 |
| Әзерләнгән экспертиза йомгаклары | 26 | 33 | 47 | 43 |
| Әзерләнгән методик документлар | 3 | 3 | 2 | 4 |
| **III. Тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыру** | | | | |
| Чаралар күрү өчен җибәрелгән тәкъдимнәр | 40 | 54 | 59 | 56 |
| Бюджетка кире кайтарылган акчалар һәм күрелгән чаралар (мең сумнар) | 1 454 450,0 | 1 750 696,8 | 1 922 464,6 | 2 530 004,3 |
| Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча прокуратура һәм хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны (берәмлек) | 51 | 57 | 55 | 58 |
| Хисап палатасы тикшерү материаллары буенча административ җаваплылыкка тарту турында суд һәм башка вәкаләтле органнар кабул иткән карарлар саны | 66 | 71 | 35 | 33 |
| Татарстан Республикасы Хисап палатасы материаллары буенча кузгатылган җинаять эшләре саны | 3 | 1 | 3 | 4 |

## Тикшерү- ревизия эшчәнлеге

2012 елда Хисап палатасының тикшерү эшчәнлеге бюджет чараларын һәм дәүләт милкен кулланганда бозуларны ачыклауга гына түгел, ә кисәтү чаралары үткәрүгә дә юнәлтелде.

Хисап палатасы тарафыннан **53** тикшерү-ревизия чарасы үткәрелде, **483** объект тикшерелде. Тикшерелгән чаралар күләме **112,9 млрд.** сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү чаралары 11 министрлыкта, 8 муниципаль берәмлектә үткәрелде.

Моннан тыш, камераль рәвештә республика бюджеты чараларын 33 төп кулланучының еллык бюджет хисабы (2011 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапны тышкы яктан тикшерү кысаларында) һәм югары дотациягә ия 12 муниципаль берәмлекнең 2011 ел өчен бюджет үтәлеше турында хисаплары тикшерелде.

Татарстан Республикасы **торак-коммуналь комплексны үзгәртеп кору һәм модернизацияләүгә юнәлгән дәүләт чараларын файдалануга нәтиҗәлелек аудиты** үткәрелде.

Торак-коммуналь хуҗалыкта чара һәм проектларны финанслауга 2005-2011 еллар эчендә бюджеттан 29,9 млрд.сум акча бирелгән.

Тулаем алганда торак-коммуналь хуҗалыгын үзгәртеп кору һәм модернизацияләү Программасы, кулланучыларга коллектив (гомумөй) исәп приборлары күрсәткечләре буенча коммуналь ресурсларны җибәрүгә күчү Республика адреслы программасының планлы күрсәткечләренә ирешелгән. Республиканың күп күрсәткечләре гомумроссия дәрәҗәсен узып китә.

2008 -2011 еллар эчендә ТКХ өлкәсендә төзелеп бетмәгән объектлар саны 151 дән 88 гә кадәр кимегән (гомуми бәясе 2 478,3 млн сум).

Республика районнары һәм шәһәрләре буенча коммуналь хезмәтләргә тарифларның сизелерлек дифференциациясе билгеләп үтелгән.

Торак-коммуналь комплекс предприятиеләрен финанс ягыннан сәламәтләндерү буенча күрелгән чаралар кредит һәм дебитор бурыч күләменең сизелерлек кимүенә китермәгән.

Торак-коммуналь комплекс предприятиеләренең дебитор һәм кредит бурычы турында мәгълүмат




Анализланган вакыт аралыгында ТКХ да төп фондларның тузу дәрәҗәсе бераз кими, шул ук вакытта ул югары булып кала. Коммуналь челтәрләрнең тузуы һәм авария хәлендә булуы ресурсларны кулланучыларга ташыганда югалтуларга китерә.

Энергия белән тәэмин итүче оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү резервлары ачыкланган.

«Таткоммунпромкомплект» ААҖда гомуми бәясе 245 134,1 мең сумлык лизинг килешүләре буенча түләмәүчеләрдән тартып алынган кулланылмый торган техника һәм җиһаз булган. Кулланылмый торган матди мөлкәтне хуҗалык әйләнешенә кертү тәртибе билгеләнмәгән.





Торак фонды белән идарә итүче оешмалар эшчәнлеге житәрлек дәрәҗәдә үтә күренмәле түгел. Сайтларында урнаштырылган мәгълүмат һәрвакытта да куелган таләпләргә туры килми. Идарәче компанияләр эшчәнлеген тикшерүнең гамәлдәге системасы аларның икътисадый нигезләнмәгән чыгымнар тоту, эшләр башкаруга намуссыз оешмаларны тарту фактларын китереп чыгара.

Күпфатирлы йортларда капиталь ремонт ясау вакытында эшләрне сыйфатсыз башкару һәм эш күләмен арттырып күрсәтү фактлары ачыкланды.

Нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары буенча гомуми күләме 373 450,4 мең сум булган бозулар ачыкланды, 364 077,2 мең сумы юкка чыгарылды.

Муниципаль берәмлекләргә (эксплуатацияләүче оешмаларга) гомуми күләме 138 429,0 мең сум булган төзелгән һәм чынбарлыкта эксплуатацияләнә торган объектлар тапшырылган.

«Таткоммунпромкомплект» ААҖ уставлы капиталы 180 000,0 мең күләмендә бюджет инвестицияләре суммасына арткан.

Төзелеп беткән оъектлар буенча калган 22 442,4 мең сум күләмендәге бюджет акчалары башка объектларга бүлеп бирелгән.

23 205,8 мең сумлык бухгалтер исәбен бозулар юкка чыгарлыган.

«Таткоммунпромкомплект» ААҖ генераль директорының лизинг буенча урынбасары һәм Казан шәһәренең Мәскәү, Авиатөзелеш һәм Совет районнары торак-коммуналь хуҗалык идарә оешмаларының 7 вазыйфаи заты дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

Казан шәһәренең Мәскәү һәм Идел буе районнарында күпфатирлы йортларда капиталь ремонт ясау буенча эшләрне башкармау фактлары буенча Россия Федерациясе Җинаять кодексының «Алдау» 159 номерлы маддәсе буенча җинаять эше кузгатылды.

Торак- коммуналь хуҗалыкта чараларны куллануның нәтиҗәлелеген арттыру максатында 50дән артык тәкъдим әзерләнде.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына:

1. Күпфатирлы торак йортларны капиталь ремонтлау программаларын төзүне торак йортларның индивидуаль җылыту системасына күчү буенча республика программаларын, торак пунктларының үзәкләштерелгән һәм үзәкләштерелмәгән җылыту системасын үстерү буенча озак вакытка исәпләнгән планнарын истә тоткан хәлдә тормышка ашырырга;

2. Дәүләт катнашы белән яңа ТКХ объектларын төзү һәм эшләп килүчеләрен реконструкцияләү буенча проектларның максатка ярашлылыгы һәм техник-икътисади нәтиҗәлелеген алдан бәяләүне үткәрү тәртибен расларга;

3. Энергия ресурсларын куллану һәм торак-коммуналь хуҗалыкта энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү һәм энергияне саклау буенча чараларны тормышка ашыруын мониторинглау региональ системасын камилләштерергә, ТКХта энергия саклауның нәтиҗәлелеге торышы турындагы мәгълүматның ачык булуын тәэмин итәргә;

4. Торак-коммуналь комплексның энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү тармак программасын эшләргә;

5. Торак-коммуналь хуҗалыкта энергия сервисы контрактлары төзү практикасын кертүне тәэмин итәргә;

6. Идарә итүче компанияләр эшчәнлеген тикшерүне арттыру вариантларын карарга;

7. Күпфатирлы йортларга хезмәт күрсәтү өчен подряд оешмаларын сайлап алу буенча бәйгеләр үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәр эшләп чыгарырга;

8. ТКХ өлкәсендә тәмамланмаган инвестицион проектлар һәм программаларны инвентаризацияләү үткәрергә, тәмамланмаган төзелеш күләмен киметү максатында аларның өстенлелеген билгеләргә;

9. Күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр өчен, шул исәптән маневрлы фондлар төзү, вакыты чыккан дебитор бурычны киметү буенча чаралар күрергә;

10. Күпфатирлы торак йортларны җылылык куллану белән идарә итүне автоматлаштырылган челтәр белән җиһазлау, җылыту приборларының

җылылык бирүен шәхси көйләүне кертү буенча чаралар күрергә тәкъдим ителде.

Нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумында каралды. 2012 елның 28 декабрендә Хисап палатасы тәкъдимнәрен исәпкә алган хәлдә торак-коммуналь хуҗалык комплексында бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар комплексын үз эченә алган 2451-р номерлы **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителде.**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча Мәдәният министрлыгында һәм аңа караган ведомство учреждениеләрендә **энергия ресурсларын кулланганда бюджет чараларын куллануга нәтиҗәлелек аудиты** үткәрелде. 2011-2015 елларга Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге ведомство программасының тулы күләмдә тормышка ашырылмавы ачыкланды. Министрлык тарафыннан 2012 елның 1 июленә 34 программа чарасының икесе генә үтәлгән.

2007-2010 елларда коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә мохтаҗлыкны планлаштыру Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы җибәргән индекс – дефляторларны кулланып, энергия куллануның расланган нормативларын исәпкә алмыйча башкарылган.

Мәдәният министрлыгы ведомствосына караган учреждениеләр тарафыннан энергияне саклау буенча энергия йөртүчеләрне куллану күләмен киметүне тәэмин итүче кирәкле чараларны тулы күләмдә кулланмаганнар, бу аларны сатып алу өчен 69 100 мең сум күләмендә бюджет чараларын нәтиҗәсез куллануга китергән.

Күп очракларда заказ урнаштыруның аерым катнашучыларына хокуксыз рәвештә таләпләр кую нәтиҗәсендә капиталь ремонт, шул исәптән энергия саклау буенча чаралар, үткәрүгә гомуми күләме 14 400 мең сум булган дәүләт контрактлары аукционда катнашучы бердәнбер оешма – «НК Стройиндустрия» ҖЧҖ белән төзелгән.

Нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары буенча ачыкланган бозуларның гомуми күләме 104 862,0 мең сум тәшкил итә.

Энергия саклау буенча чараларны үтәү һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеген күтәрүне тәэмин итү максатында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына:

1. үткәрелгән аудит нәтиҗәләрен исәпкә алып, 2011-2015 елларга энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге ведомство программасына үзгәрешләр кертергә;
2. 2011-2015 елларга Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге республика программасын тормышка ашыру кысаларында энергия саклау һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чаралар үтәлешен даими тикшереп торырга;
3. мәдәният учреждениеләрен һәм ведомствога караган башка учреждениеләрне энергия исәпләүче приборлар белән җиһазлауны, булган приборларны эш халәтенә китерүне тәэмин итәргә;
4. чагыштырма шартларда 5 ел эчендә 15 процентка кимету максатында, ел саен энергия ресурсларын куллануны 3 процентка киметүне тәэмин итәргә;
5. ведомствога караган учреждение һәм оешмаларда даими рәвештә энергетик тикшеренүләр оештырырга;
6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 4 декабрендә кул куелган 592 номерлы «Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге чараларын тормышка ашыруда катнашучыларны матди кызыксындыру турында Нигезләмәне раслау турында» карары раслаган матди кызыксындыру механизмын тормышка ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм бюджет өлкәсенең тармак учреждениеләре энергия ресурсларын кулланганда бюджет чараларын тотуның нәтиҗәлелегенә аудит нәтиҗәләре турында хисап 2013 елның гыйнварендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча комитеты утырышында каралды.

2009-2010 елларда һәм 2011 елның үткән вакыт аралыгында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын **бушлай уку әдәбияты**

**белән тәэмин итүгә** бүлеп бирелгән бюджет чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерү 2010 елда уку елы башында складларда 200 меңнән артык, 2011 ел сентябрендә – 182 мең дәреслек булуын ачыклады. 5 613,3 мең сум күләмендә бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелеге тәэмин ителмәгән. Шул ук вакытта кайбер мәктәпләрдә укучыларның ата-аналарыннан дәреслекләр сатып алуга акча җыелган.

Республика бюджетыннан дәреслекләрне саклау һәм уку йортларына илтеп бирү өчен 19 млн. сум акча бүлеп бирелгән. Шуның белән бергә, тикшерүләр барышында Әгерҗе, Әлмәт, Югары Ослан, Питрәч, Түбән Кама муниципаль районнарында һәм Яр Чаллы шәһәрендә 2011/2012 уку елында 20 меңнән артык дәреслекне мәктәпләр үзләре алып кайтуы ачыкланган.

Әдәбиятны вакытында кайтарып җиткерүне тикшерү Министрлык тарафыннан тулы күләмдә тормышка ашырылмый. Уку әдәбиятын вакытында китереп җиткермәү өлешендә контрактлар шартын бозу буенча претензияләр эше үткәрелмәгән.



Тикшерү нәтиҗәләре 2012 елның июнендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы көрәш буенча Совет утырышында каралды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 613,3 мең сум күләмендә бозулар юкка чыгарылган, уку әдәбияты уку йортларына тулы күләмдә кайтарылган.

Мәктәпләрне вакытында дәреслекләр белән тәэмин итмәүдә гаепле булган Мәгариф һәм фән министрлыгының аерым вазыйфаи затлары, шул исәптән ике министр урынбасары, дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

2010-2011 елларда **өлкән яшьтәгеләр һәм инвалидлар өчен интернат-йортларга** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерү үткәрелде.

Интернат- йортларның күбесе автоном учреждениеләргә әйләндерелде. Шулай булса да, оештыручы – Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль саклау министрлыгы тарафыннан оештыру документларына үзгәрешләр кертү буенча чаралар күрелмәгән. «Автоном учреждениеләр турында» Федераль закон нормаларын бозып, күзәтү советлары тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлегенең планы каралмаган һәм расланмаган, аерым учреждениеләр үзләренең эшчәнлеге һәм аларга беркетелгән милекне куллану турында еллык хисапларын бастырып чыгармаган.

Күп интернат-йортларда социаль хезмәт күрсәтә торган белгечләр җитәрлек түгел. Интернат-йортларның 30%ында гына психологлар, юристлар, 60% ында социаль хезмәт күрсәтү белгечләре бар. Интернат-йортта бер яшәүчегә хезмәт күрсәтүче персонал саны да шактый аерыла: Кайбыч интернат-йортының 20 эшчесенә – 25, Тукай интернат-йортының 23 эшчесенә 56 кеше туры килә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча 305 016,3 мең сумлык бозулар ачыкланган.

Мамадыш һәм Казан интернат-йортларында башкарылмаган эш күләмнәре өчен 2 778,8 мең сум күләмендә түләү үткәрелүе ачыкланган. Тикшерү нәтиҗәләре буенча подряд оешмасы исәбеннән 1 936,4 мең сум акча алынган, 805,4 мең сумга өстәмә эшләр башкарылган.



Казан өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорт

Арча, Буа һәм Казан интернат-йортларында төрле бозулар, шул исәптән булган ихтыяҗдан артык күләмдә ясалган килешүләр буенча поставщикларга акча күчерү, туклану ризыклары җитмәүчелек һәм башкалар белән бәйле гомуми күләме 540,3 мең сумга бозулар табылган. Тикшерү вакытында артык чаралар приходланган, җитмәгән чаралар кире кайтарылган.

Арча һәм Югары Ослан интернат-йортларында азык-төлек продуктлары китерүгә килешүләр гомуми бәясе 3 329 мең сумга сатып-алулар үткәрелмичә генә төзелгән.

Продуктларның аерым төрләре буенча куелган туклану нормалары тотылмый. Интернат-йортларда яшәүчеләрнең ашау-эчүе ярма, кузаклы һәм макарон эшләнмәләр буенча норманы арттырып җитештерелә, шул ук вакытта күп очракта олы кешеләр ит, балык, җиләк-җимешне тиешенчә алмый. Мәсәлән, Тәтеш интернат-йортында кош итен куллану – нормадан 9%, балыкныкы 42% тәшкил иткән.

Аерым очракларда, китерелә торган товарларның төрлелеге һәм саны килешү шартларына туры килмәгән, туклану продуктларының бер өлеше килешүдә куелганнан югарырак бәя белән китерелгән.

Килешү шартлары буенча Югары Ослан интернат-йортына «Звениговский» ит комбинаты тарафыннан кг 150 сумнан сарделька китерү каралган, чынлыкта исә бәя 170 сум була. Арча интернат-йорты һәм «Айракс» сәүдә йорты» ҖЧҖ арасында килешү сатып алына торган азык-төлек продуктларының саны һәм төрлелеге күрсәтелмичә төзелгән.

Мамадыш интернат-йортында биналарны арендага бирүдән килгән чараларның кереп җитмәгәнлеге ачыкланды. Казан интернат-йортында 845,1 мең сумлык товар-матди байлыклар 2 елдан артык кулланылмаган.

Милекне файдалану белән бәйле бозулар күләме 287 059,3 мең сум тәшкил итә. Арча, Югары Ослан, Мамадыш интернат-йортларында 5 634,9 мең сумлык күчемсез милек объектлары милек хокукына мәҗбүри дәүләт теркәвен үтмәгәннәр; Казан интернат-йортында 280 565,3 мең сумлык җир участогы исәптә күрсәтелмәгән. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җир участогы исәпкә куелды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча барлыгы 294 572,3 мең сумлык бозулар юкка чыгарылды.

Арча, Буа, Югары Ослан, Мамадыш һәм Казан өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортларының 7 вазыйфаи заты дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

2010-2011 елларга **метрополитен төзелешенә** бүлеп бирелгән бюджет чараларының максатчан һәм нәтиҗәле файдаланылуын тикшерү 474 906,8 мең сумлык бозуларны ачыклады.

Җир асты транспорт корылмаларын төзү буенча дирекция тарафыннан 145,5 млн.сум күләмендә бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеге тәэмин ителмәве ачыкланды: сатып алынган җиһазларның кулланылмаган, чаралар озак вакытка – 20 айга кадәр – дебитор бурычына тотылганлыгы ачыкланды. Тикшерү барышында 59,6 млн.сум төзелеш-монтаж эшләрен түләүгә җибәрелә, 1,4 млн сум бюджетка кире торгызыла.

Дирекция балансында чынлыкта МУП «Метроэлектротранс» тарафыннан кулланылган гомуми бәясе 205 116,7 мең сумлык җиһаз саналган. Тикшерү материаллары буенча Татарстан Реапубликасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының милекне муниципаль мөлкәткә тапшыру турында тиешле боерыгы әзерләнде.

Гомуми бәясе 124 329,5 мең сумлык бухгалтер хисабын бозу очрагы ачыкланды. Тикшерү барышында 91 385,0 мең сумлык җиһаз тиешле хисапларда чагылыш тапкан, 32 944,5 мең сум кредит бурычы бухгалтер хисабына яңадан торгызылган.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча барлыгы 390 456,4 мең сумлык бозулар төзәтелде (шул исәптән бюджетка кире кайтарылды).

Җир асты транспорт корылмалары төзү буенча дирекциянең финанс бүлеге башлыгы дисциплинар җаваплылыкка тартылды.



**Сәламәтлек саклау учреждениеләрен төзү һәм реконструкцияләүгә** бүленеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалануны тикшерү төзелеп бетмәгән объектлар буенча 2010 елдан калган 2 503,8 мең сумлык бюджет чараларын кулланылмавын ачыклады.

Төзелеп бетмәгән төзелеш составына моннан 7 ел элек төзелә башлаган ике объект керә.

Республика клиник хастаханәсендә капиталь ремонт буенча эшләр бәясен 1 328,6 мең сумга арттыру ачыкланды. Балык Бистәсе муниципаль районы үзәк район хастаханәсендә кайтарганнан бирле елдан артык 921,9 мең сумга сатып алынган җиһаз кулланылмаган, 1 328,6 мең сумлык ремонт эшләре сыйфатсыз үткәрелгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча барлыгы 40 678,3 мең сумлык бозулар ачыкланды, 39 756,4 мең сумга – юкка чыгарылды.

**Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе** буенча Казан шәһәрендә юл катламын чокыр ремонты буенча, юл-урам челтәре объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне, подрядчыларның гарантия йөкләмәләрен үтәвен тикшерү үткәрелде.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсендә бюджет чараларын тотканда Россия Федерациясенең Бюджет кодексының 34 маддәсе тарафыннан билгеләнгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелек принцибы сакланмаган. Юлларның кайбер өлешендә техник-эксплуатация сыйфатлары билгеләнгән таләпләргә туры килми торган асфальт-бетон каплавының өске катламы салынган. 5 613,4 мең сумлык бюджет чаралары нәтиҗәсез файдаланган.

Подрядчы оешманың 5 объекты буенча эшләрне башкару вакытын бозган өчен гомумән алганда 3 443,4 мең сум булган штраф санкцияләре билгеләнмәгән.

Авиатөзелеш, Яңа Савин һәм Вахитов районнарында юл ремонтаган чакта эш күләмен арттыру очраклары ачыкланды.



Автомобиль юлының Гаврилов урамы буенча уза торган өлеше

Төзелеш, реконструкцияләү яки капиталь ремонтлау эшләре үткәрелгән күп кенә объектларда төрле дефектлар (чокыр, ярыклар) табылды.

Заказчы тарафыннан асфальт-бетон сыйфатын лаборатория шартларында тикшерү үткәрелмәгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Капиталь төзелеш һәм реконструкцияләү идарәсе тарафыннан «Каздорстрой» ААҖ, «Стройхимсервис» ҖЧҖ подрядчы оешмаларга дәгъва белдерелде. Гарантия йөкләмәләрен башкару кысаларында кисәтүләрне юкка чыгару буенча эш алып барыла.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим ителде.

Тикшерү материаллары буенча Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан оператив чаралар үткәрелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләрендә **балалар бакчаларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлауга** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет акчаларын кулллануны тикшерү үткәрелде. .

Татарстан Республикасында балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә җәлеп итү 73,7 % (Россиядә – 63,8 %, Казанда – 75,3 %) тәшкил итә.

Аерым муниципаль берәмлекләрдә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең артык тыгызлануы күзәтелә. Республика буенча уртача

һәр 100 мәктәпкәчә урынга 107 бала туры килә: авыл җирлекләрендә – 89, шәһәр балалар бакчаларында – 114.

2009-2011 еллар эчендә мәктәпкәчә балалар белем бирү учреждениеләре саны – 1 903тән 1926 га, урыннарның гомуми саны – 151 953 тән 168 748 гә, тәрбияләнүчеләр 162 278 дән 181 182 гә артты.




2010-2012 елларга балалар бакчаларын төзү һәм капиталь ремонтлауга Татарстан Республикасы бюджетыннан 3 326 369,0 мең сум акча бүленә.

47 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе төзелде, 19 реконструкцияләнде, 22 мәктәпкәчә белем системасына кире кайтарылды, эшли торган балалар бакчаларында 304 өстәмә төркем оештырылды.

Башкарылган эшләрнең бәясен 2 184,8 мең сумга арттырып күрсәтү фактлары ачыкланды. Тикшерү вакытында әлеге бозулар юкка чыгарылды.

Аерым объектлар буенча башкарылган төзелеш һәм ремонт эшләренең техник кимчелекләре ачыкланды. Татарстан Республикасының Төп инвестиция-төзелеш идарәсе тарафыннан подрядчы оешмалар тарафыннан кисәтүләрне бетертү буенча эш оештырылды.

Дәүләт заказын формалаштыру, урнаштыру һәм үтәлешен тикшерү системасының һәм төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт объектларын эксплуатацияләүнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатында, Хисап палатасы барлык кызыксынучы яклар: дәүләт заказчысы, тармак министрлыгы, эксплуатацияләүче оешма, муниципаль хакимият органнары гамәле регламентын эшләү һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте дәрәҗәсендә раслау инициативасы белән чыкты.

Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләрендә балалар бакчаларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлауга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет чараларын куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча хисап 2013 елның гыйнварендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты утырышында каралды.



Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына караган **ятим һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен дәүләт ведомство учреждениеләрен үстерүгә** бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү үткәрелде.

Тикшерү вакытына опека һәм попечительлек органнарында исәптә 12 320 бала (республикада яшәүче балаларның гомуми санының 1,7%ы) тора, аларның 11 102се гаиләләрдә тәрбияләнә иде.

2007-2011 елларда республикада балалар йортларында тәрбияләнүче балалар санының кимү тенденциясе күзәтелә (2007 ел – 861 бала, 2011 елда – 636 бала).

Күпчелек (Лаеш, Алабуга, Яшел Үзән, Норлат, Казан шәһәренең Идел буе һәм Киров районнары, Яр Чаллы шәһәренең «Мәрхәмәт») балалар йортлары өчен Министрлык тарафыннан оештыру-хокукый формасын ачыклау мәсьәләсе хәл ителмәгән, ә аерым очракларда 2012 елга дәүләт йөкләмәләре җиткерелмәгән. Биналар тузу сәбәпле аларга капиталь ремонт сорала. Аерым объектлар җимерек хәлдә, йокы бүлмәләре мәйданының расланган нормативлары сакланмый.

Тузу сәбәпле, биналарга капиталь ремонт үткәрү таләп ителә. Аеырм объектлар авария хәлендә, йокы бүлмәсе мәйданының расланган нормативлары үтәлми.

Продуктларның аерым төрләре буенча билгеләнгән туклану нормалары үтәлми. Балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең туклану рационында нигездә

ярма, борчак, макарон эшләнмәләре кертелгән, шул ук вакытта балалар кош ите, балык, җиләк-җимеш, яшелчәне аз күләмдә ала.

Яшел Үзән балалар бакчасында кош итен куллану 2010 елда – нормативның 36%ын, 2011 елда – 20%, 2012 елның I яртыеллыгында – 38% тәшкил итте. Казан шәһәренең Киров районы балалар йортында 2012 елның I яртыеллыгында кош ите гомумән сатып алынмаган.

Кондитер эшләнмәләрен куллану 2011 елда: Яшел Үзән балалар йортында – нормативтан 516,8%, Норлат балалар йортында – 409,8%, Лаеш балалар йортында – 247,7%, Әлмәт балалар йортында – 198,4%, Казан шәһәренең идел буе балалар йортында – 201,6% тәшкил иткән.

Тикшерү барышында барлыгы 2 139,5 мең сумлык бозулар ачыкланды.

Казан шәһәренең Идел буе һәм Киров районнары, Норлат балалар йортларында 1 641,9 мең сумлык кулланыла торган күчемсез милеккә милек хокукы теркәлмәгән.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча 1 738,3 мең сумлык бозулар юкка чыгарылды.

Ведомствога караган учреждениеләр эшчәнлеген тикшерү һәм вазыйфаи затларны җавапка тарту максатында тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрелде.

Дисциплинар җаваплылыкка Казан шәһәренең Идел буе һәм Киров районнары балалар йортының 3 вазыйфаи заты тартылды.

Тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтлек вәкилгә җибәрелде.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгында** 2010-2011 елларда Татарстан Республикасы бюджетына дәүләт унитар предприятиеләренең чиста табыш өлешендә тотып калулар һәм уставлы капиталда Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлык җәмгыятьләренең дивидендлары формасында акча күчерүләрнең тулылыгы һәм үз вакытында булуын тикшерү үткәрелде.

Татарстан Республикасы бюджетына куелган вакытка 46 058,2 мең сум – 2009 ел нәтиҗәләре буенча дәүләт унитар предприятиеләренең салым һәм башка төр түләүләрдән соң калган табышының 30%ы күчерелмәве ачыкланды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, чараларның тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына керүе билгеләп үтелде.

Хисап палатасы тарафыннан бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары тарафыннан алар артыннан билгеләнгән милекне арндага биргән очракта дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс яктан тәэмин итүне коррекцияләү буенча тәкъдимнәр әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланды. Бюджет чыгымнарын оптимитзацияләүнең тәкъдим ителгән механизмы буенча **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 9 февралендә кабул иткән 94 номерлы карары** белән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аны үтәүне финанс яктан тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертелде.

2011 ел өчен Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәттән файдалунадан аренда түләүләреннән Татарстан Республикасы бюджетына килгән кертемнәрне тикшерү нәтиҗәләре буенча республика Хөкүмәте **2012 елның 11 февралендә** «Татарстан Республикасы дәүләт милкеннән файдаланган өчен аренда түләве турында» **99 номерлы карарын** кабул итте. Татарстан Республикасы милкеннән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү максатында, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына Татарстан Республика дәүләт милкен арендалау килешүләре төзегәндә аренда түләве күләмен билгеләүне аның бәяләү эшчәнлеге законлылыгына бәйле рәвештә үткәрелә торган базар кыйммәтен бәяләү нәтиҗәләре буенча тәэмин итәргә йөкләнде.

**Салым булмаган керемнәрне куллану нәтиҗәлелеген** тикшерү барышында Татарстан Республикасы бюджетына чаралар килүнең өстәмә резервлары ачыклана.

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсен 2010-2011 еллар өчен әйләнә-тирә

мохиткә тискәре йогынты өчен түләү төсендә Татарстан Республикасы бюджетына керүче керемнәр администраторы функциясен үтәүне тикшерүгә Идарәдә 2012 елның 1 гыйнваренә исәпкә 47 788 салым түләүче басуын ачыклады. Шул ук вакытта, Федераль салым хезмәте мәгълүматлары буенча, республикада 220 866 юридик зат һәм индивидуаль эшмәкәр теркәлгән (үз эшчәнлеген туктатучылардан тыш).

Әйләнә-тирәгә тискәре йогынты ясаган өчен түләүне Идарәдә исәпкә куелучыларның гомуми саныннан 57%ы кертә.

Әйләнә-тирәгә тискәре йогынты өчен түләү кертү буенча бурычларын үтәмәүче затларны ачыклау өчен Идарә, салым органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең килешеп эшләүләре кирәк. Идарә тарафыннан бары тик 16 муниципаль район белән генә килешүләр төзелгән. Салым органнары белән килешүләр төзелмәгән.

Табигатьтән файдаланучылар белән эш буенча ведомствоара комиссия, аны төзү Килешүдә каралган, бары тик Түбән Кама муниципаль районында гына оештырылган.

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2012 елда ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча күрелгән чаралар нәтиҗәсендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре тәэсире өчен 4 086 түләүче өстәмә теркәлгән. Татарстан Республикасы бюджетына 45 470,7 мең сум өстәмә керем килгән. Үткәрелгән претензия дәгъва эше нәтиҗәләре буенча түләүләр буенча бурычның 28 441 мең сумы түләтелде.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителде.

Гомумән, тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча түбәндәге бозулар ачыкланды: Татарстан Республикасы бюджет чаралары буенча – 2 085 954,7 мең сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары – 903 927,8 мең сум, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты – 12 294,4 мең сум, күпфатирлы торак йортларга капиталь

ремонт үткәрүне финанслауда катнашу чаралары буенча – 23 116,5 мең сум, бюджеттан тыш чаралар буенча – 18 698,5 мең сум.

Комплекслы һәм тематик тикшерүләр үткәргәндә ачыкланды:

– чараларны максатсыз файдалану – 2 701,5мең сум;

– «Товарлар китерү, эшләр башкару, дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен хезмәт күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» Федераль законны бозулар – 29 300,3 мең сум;

– бюджет чараларын нәтиҗәсез куллану – 353 284,6 мең сум;

– «Бухгалтер исәбе турында» Федераль законны, исәп һәм хисапны җайга салучы башка төр норматив хокукый актларны бозулар – 1 012 758 мең сум, шул исәптән бюджет хисабын бозу, бухгалтер исәбе регистрларында һәм бухгалтер исәбе хисапларында хуҗалык операцияләре исәбе булмау;

– дәүләт (муниципаль) милке белән җитәкчелек һәм идарә иткәндә бозулар – 1 130 699 мең сум;

– бюджет законнарын башка төрле бозулар (милек хуҗасы рөхсәтеннән башка төп чаралар һәм милекне чыгымга язу, республика лизинг фонды чараларын нигезсез дебитор бурычлылыгына юнәлдерү, расланган лимитлардан артык йөкләмәләр кабул итү, хезмәт күрсәтүчеләргә булган ихтыяждан артык чаралар күчерү һ.б.) – 515 248,5 мең сум.

**2012 ел өчен**
**Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган**
**финанс бозулары төзелеше**



Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча төп бюджет чараларын бүлүчеләргә, башка бюджет процессында катнашучыларга ачыкланган бозулар буенча чаралар күрү өчен 56 күрсәтмә җибәрелде.

Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнары 95 мәгълүмати хат җибәрелде.

Хисап палатасы материаллары буенча республика районнары һәм шәһәрләренең прокурорлары тарафыннан башкарма хакимият органнары, оешма һәм учреждение җитәкчеләре адресына бюджет законнарын бозу очракларын юкка чыгару турында 50 күрсәтмә кертелде.

Дәүләт һәм муниципаль заказларны урнаштыру өлкәсендә ачыкланган бозу фактлары буенча мәгълүмат Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрелде.

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 3 вазыйфаи затны административ җаваплылыкка тартты.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча:

- тикшерү барышында (һәм аңардан соң) 2 238,8 мең сум күләмендә максаттан тыш чыгымнар кире торгызылды;
- төрле дәрәҗә бюджетларга бозуларның башка төрләре буенча 181 692,1мең сум торгызылды;
- ачыкланган бозу һәм җитешсезлекләр буенча 2 346 073,4мең сумлык чаралар күрелде.

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә тикшерү нәтиҗәләре буенча бозулар юкка чыгарылды**
(мең сумнарда)




2012 елда үткәрелгән тикшерү-ревизвия, экспертиза-аналитика чаралары буенча йомгаклау документлары Хисап палатасының 29-32 номерлы мәгълүмати бюллетеньнәрендә бастырылды, шулай ук Хисап палатасының интернет сайтында (http://www.sprt.ru) тәкъдим ителде.

# Экспертиза – аналитика эшчәнлеге

2012 елда Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды бюджетын үтәүне беренчел, агымдагы һәм соңгы тикшерүне тормышка ашырганда 108 экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде. Аларның нәтиҗәләре Хисап палатасы бәяләмәсендә чагылыш тапты.

**Беренчел тикшерү** кысаларында хисап елында Татарстан Республикасының 20 закон проектына экспертиза, шулай ук 3 норматив хокукый актлар проектына: шуларның икесе – озак вакытка исәпләнгән максатчан программа, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге проектына экспертиза үткәрелде.

**«2013 елга һәм 2014 һәм 2015 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты турында»** закон проектына экспертиза ясау буенча бюджет керемнәрен фаразлаган вакытта салым керемнәренең бюджетка килүенең билгеләнгән нормативлары үтәлгәнлеге, кире кайтарылмый торган чаралар күләменең федераль бюджетта Татарстан Республикасы өчен каралган күрсәткечләренә туры килгәнлеге расланды.

Республика бюджты проекты федераль бюджеттан бюджетара трансфертларының күп күләме регионнар буенча бүленмәгән шартларда төзелде. Бу җәһәттән федераль бюджеттан килергә тиешле фаразланган керем күләме төгәл түгел һәм тәгаенләнәчәк.

Башка еллардагы кебек үк, республика бюджеты социаль юнәлешле булып кала, 2013 елда социаль өлкәгә киткән чыгымнарның чагыштырма авырлыгы 68% тәшкил итә.

Бәяләмәдә 2013 ел һәм 2014 һәм 2015 еллар планлы вакытына республика бюджетының закон чыгаручы органга кайбер республика программаларының билгеләнгән тәртиптә расланмаган хәлдә кертелүе күрсәтелә.

Озак вакытка исәпләнгән кайбер республика максатчан программаларын финанслау программа паспортлары буенча расланганнан

кимрәк дәрәҗәдә каралган. Бу җәһәттән Хисап палатасы тарафыннан бюджет ассигнованиеләренең планлаштырылган күләмен истә тоткан хәлдә программаларның параметрларын тәгаенләү тәкъдим ителде.

Экспертиза нәтиҗәләре буенча 2014 һәм 2015 еллар планлы вакытына сыйныф белән җитәкчелек иткән өчен акчалата түләүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен тәгаенләү тәкъдим ителде. Бу күрсәтелгән түләүләрне финанс яктан тәэмин итүнең 2014 елдан региональ дәрәҗәгә күчерү белән бәйле.

Финанс елы барышында Россия Федерациясе субъектлары буенча федераль бюджеттан бүленә торган өстәмә субсидияләр алу өчен шартлар үтәү максатында, Закон проекты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә федераль программалар чараларын финанслауда катнашуга 3 498 742,3 мең сум чара каралган.

**«2013 елга һәм 2014 һәм 2015 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында»** закон проектына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча 2013 елда Фонд бюджетына өстәмә керем килү резервлары барлыгы ачыкланды. Шулай ук бәяләмәдә Россия Федерациясе гражданнарына Татарстан Республикасы территориясендә бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы чараларын финанс яктан тәэмин итүгә Фонд бюджеты чыгымнары күләме Закон проектын төзегән вакытка 2013 елга федераль дәрәҗәдә расланган медицина ярдәменең норматив күләме, медицина ярдәме бирәмлегенә финанс чыгымнар нормативы, кеше башына нормативлар булмаган шартларда билгеләнде.

**2012 елга һәм 2013 һәм 2014 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында законнарга үзгәрешләр кертү турында** закон проектларына бәяләмәләрдә хисап елында күзәтелгән тенденцияләрне исәпкә алган хәлдә керемнәрнең аерым төрләре буенча бюджет күрсәткечләрен тәгаенләү, шулай ук бюджет дефицитын финанслау чыганаклары күләмен тәгаенләү буенча тәкъдимнәр ясалды.

2012 елга һәм 2013 һәм 2014 еллар планлы вакытына Татарстан Республикасы бюджеты турында законга үзгәрешләр кертү нигездә салым һәм салым булмаган керемнәрнең аерым төрләре буенча фаразланган күрсәткечләрне тәгаенләү, федераль бюджет, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджеты, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты һәм «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды» дәүләт корпорациясеннән килгән кире кайтарылмый торган керемнәр күләме үзгәрү белән бәйле.

**«2011 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»** Татарстан Республикасы закон проектына экспертиза үткәрелде һәм бәяләмә әзерләнде. Бәяләмәдә Закон проектында һәм аның кушымталарында чагылыш тапкан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре, чыгымнары, дефицитын финанслау чыганаклары күрсәткечләре тышкы тикшерү барышында расланганлыгы билгеләп үтелде.

**«2011 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында»** Татарстан Республикасы закон проектын экспертизалау нәтиҗәләре буенча Закон проектында чагылыш тапкан Фонд бюджеты үтәлеше күрсәткечләрендә туры килмәүләр ачыкланмады.

**«Оешма милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 1 августында кул куелган 57-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында»** Татарстан Республикасы Законы проекты буенча Хисап палатасы тарафыннан Закон проектын кабул итү 2012 елга һәм 2013 һәм 2014 еллар планлы вакытына, республика бюджетының баланслылыгын саклау максатында, аның төшеп калган керемнәрен компенсацияләү механизмы һәм чыганакларын билгеләү һәм күрсәткечләрен тәгаенләүне таләп итәчәге билгеләп үтелде.

Шулай ук «Оешма милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 маддәсенең 2 пунктына үзгәрешләр кертү турында», «Салым

салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкалары билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 маддәсенең 1 пунктына үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасының Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасының оешма-резидентлары өчен керемгә салым буенча салым ставкалары билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасына инвестицион салым кредиты турында», «Татарстан Республикасы территориясендә патентлы салым салу системасын кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектларына финанс-икътисадый экспертиза үткәрелде.

Хисап елында **«2012-2015 елларга Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү»** озак вакытка исәпләнгән максатчан программа проектына һәм **«2011-2015 елларга Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү» озак вакытка исәпләнгән максатчан программаның «Аренда торагы базарын үстерү»** подпрограммасы проектына экспертиза үткәрелде.

**«2012-2015 елларга Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү»** программасын экспертизалау нәтиҗәләре буенча программа проектында бюджеттан тыш чаралар җәлеп итү механизмының билгеләнмәве, программа чараларын тормышка ашыруның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булмавы, килеп чыккан пычрану һәм әйләнә-тирә мохиткә негатив тәэсир итү дәрәҗәсе күрсәткечләренең мәгънәсе тәкъдим ителмәве ачыкланды, бу программа чараларын тормышка ашыруны башлау моментына башлангыч шартларны билгеләү һәм аларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү мөмкинлеген юкка чыгара. Төрле бүлекләрдә бирелгән программа чаралары нәтиҗәләрен бәяләү нең төп максатчан индикаторларын сан һәм эчтәлек буенча эчке яктан килештерү максатында эшләп бетерү кирәклеге билгеләп үтелде.

**«2011-2015 елларга Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү» озак вакытка исәпләнгән максатчан программаның «Аренда торагы базарын үстерү»** подпрограммасы проектына экспертиза үткәрү барышында Подпрограмманы тормышка ашыруның көтелгән аерым соңгы нәтиҗәләре конкрет исәпләнә торган мәгънәгә ия булмавы, планлаштырылган күләмдә финанслауга ихтыяҗны раслаучы мәгълүмат булмавы билгеләп үтелде. Исәпләгән чакта корректировка коэффициентын куллануны күздә тотучы пунктларда торак фондның (аренда торагы) төре тәгаенләнмәгән. Моңа бәйле рәвештә идарә итүче компанияләрнең чиксез саны тарафыннан льготалы коэффициент куллану куркынычы ачылды. Программаның аерым нигезләмәләрен салым законнары белән тәңгәлләштерү кирәклеге билгеләп үтелде.

**Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге** проектына бәяләмәдә Хисап палатасы тарафыннан Тәртипне максатчан индикаторларга һәм дәүләт программасы күрсәткечләренә гомуми таләпләр белән, аерым алганда, исәпләнә торган сан мәгънәсе еллар буенча билгеләү мәҗбүрилеген һәм дәүләт статистика күзәтүе мәгълүматлары нигезендә максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләрнең ирешелгән мәгънәләрне билгеләү мөмкинлеге белән тулыландыру тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бирелә торган Татарстан Республикасы бюдҗеты үтәлеше турындагы Хисапка анализны, бюджет процессында катнашучыларның квартал хисабын тикшерүне үз эченә алган **оператив тикшерү** кысаларында керем һәм чыгым маддәләренең күләм һәм төзелеш буенча үтәү, дефицитны финанслау чыганакларыннан чаралар җәлеп итү һәм бюджет йөкләмәләре лимитын тоту дәрәҗәсе бәяләнде.

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен анализлау барышында чыгымнарны үз вакытында үтәү, шул исәптән Татарстан Республикасының игълан ителгән норматив йөкләмәләрен, максатчан программаларны

тормышка ашыруга, дәүләт бурычы торышы һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнарына, бюджет дефицитын каплауга чаралар җәлеп итүгә каралган чараларны үзләштерү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде.

Оператив тикшерү нәтиҗәләре буенча 2012 елда республика бюджетыннан хокукый нигездә тиешле субвенцияләр бирүне урнаштыру өчен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына аерым категория гражданнарга акчалата түләүләрне тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында» Татарстан Республикасы Законыннарын гамәлгә кертергә кирәклеге билгеләп үтелде.

Хисап палатасының Татарстан Республикасы бюджетының агымдагы үтәлеше буена бәяләмәләрдә бирелгән кисәтү һәм тәкъдимнәре истә тотылган.

Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетының 2012 елның гыйнвар-июнь айлары өчен үтәлешен оператив тикшерү нәтиҗәләре буенча Хисап палатасы тарафыннан Фонд бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Программаны раслау турында Министрлар Кабинеты карары тарафыннан расланган Фонд чаралары хисабына республика территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы чараларын финанслау күрсәткечләренең килешмәве ачыкланды.

Бу җәһәттән Татарстан Республикасы Премьер-министрына мәгълүмати хат юлланды. Килешмәү 2012 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турындагы Законга үзгәрешләр кертү юлы белән юкка чыгарылды.

**Соңгы** тикшерү кысаларында Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Хисап палатасы турында Закон нигезендә 2011 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапка һәм Татарстан

Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапка тышкы тикшерү үткәрелде.

2011 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапны тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча республика бюджеты үтәлеше турында еллык хисапта мәгълүматларның тулы һәм дөрес чагылыш тапмау фактлары ачыкланмады.

Республика бюджетының фактик керем һәм чыгымнарын анализлау нәтиҗәләре, закон тарафыннан расланган күрсәткечләрне үтәү дәрәҗәсе, ачыкланган тайпылыш сәбәпләре 2011 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапка бәяләмәдә тәкъдим ителде.

2011 ел өчен республика бюджеты үтәлеше турында Хисап күрсәткечләрен раслау өчен бюджет чараларын 33 төп кулланучының еллык бюджет хисабын тикшерү үткәрелде. Керемнәр администраторы функцияләрен тиешсез башкару, расланган лимиттан югарырак күләмдә йөкләмәләр кабул итү, киләсе финанс елы түләүләре хисабына чыгымнар башкару кебек Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы Хисап күрсәткечләренә тәэсир итми торган фактлар ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча бозуларга юл куйган министрлык һәм ведомстволарга Хисап палатасы тарафыннан чаралар күрү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен тәкъдимнәр кертелде.

2011 ел өчен Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапка тышкы тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча 2011 елда Фонд бюджетына күчкән керемнәрне чагылдырган чакта җитешсезлекләр ачыкланды.

**Республиканың югары дотацияле муниципаль районнарының** (Әгерҗе, Апас, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кукмара, Мамадыш, Менделеевск, Мөслим, Саба, Сарман, Чистай) **2011 ел өчен бюджетлары үтәлеше турында еллык хисапларын** тышкы яктан тикшерү барышында түбәндәге бозулар ачыкланды:

- җирле бюджет чараларының төп администраторлары тарафыннан кулланылган керемнәр буенча хисап төзелмәгән;

- бюджет чараларын төп кулланучыларның кайберләре еллык бюджет хисабы төземәгән, кайбер төп кулланучылар тарафыннан җыелма еллык бюджет хисабын төзү буенча функцияләр тулы күләмдә башкарылмаган;

- киләсе финанс елы түләүләре хисабына чыгымнар (арттырып түләүләр) ясау фактлары ачыкланды;

- муниципаль районнар бюджеты расланганда, аларга үзгәрешләр керткәндә һәм муниципаль районнар бюджетлары үтәлеше турындагы еллык хисапларгы раслаганда бюджет законнары нормалары (бюджет чыгымнарының ведомство төзелеше, бюджет дефицитын финанслау чыганаклары буенча чыгымнары күрсәткечләре аерым кушымта булып расланмаган) тулы күләмдә үтәлмәгән, бюджет классификациясе кодларын куллану тәртибе, керемнәр һәм чыгымнар, бюджет дефицитын финанслау чыганаклары буенча аерым күрсәткечләрне чагылдыру таләпләре истә тотылмаган, бюджет турындагы карарның текст маддәләре кушымтада чагылыш тапкан мәгълүматлар белән тәгаенләштерелмәгән.

Тышкы тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмәләр муниципаль районнар башлыкларына юлланды.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бюджет хисабын төзү буенча эшләр оештырганда муниципаль берәмлекләргә методологик яктан ярдәмне көчәйтү турында тәкъдим белән мәгълүмати хат юлланды.

**«2012-2015 елларга Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү»** тормышка ашыру кысаларында тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары үткәрү өчен тышкы дәүләт финанс тикшерүе стандартлары эшләп чыгарыла. 2012 елда **«Тикшерү чарасы үткәрүнең гомуми кагыйдәләре»** дип аталган **тышкы дәүләт финанс тикшерүе стандарты** эшләп чыгарылды. Ул тикшерү чараларына әзерләнү, үткәрү, нәтиҗәләрен теркәүгә караган гомуми таләпәрне билгели.

# Коррупциягә каршы тору буенча эшчәнлек

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» федераль закон нигезендә тышкы финанс тикшерүе органнарының гомуми вәкаләтләренә коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән чараларга катнашу кертелә. Әлеге вәкаләтләр «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» закон белән дә беркетелгән.

Хисап палатасы үткәргән комплекслы һәм тематик тикшерү чаралары нәтиҗәләре күрсәткәнчә, коррупция чагылышы булырга мөмкин тармаклар булып түбәндәгеләр тора: дәүләт (муниципаль) заказын урнаштыру һәм үтәү, дәүләт (муниципаль) милке, җир ресурслары белән идарә итү; дәүләт ярдәме күрсәтү.

**Дәүләт (муниципаль) заказлар урнаштыру һәм үтәү** этапларында түбәндәгеләр ачыклана: бәйге процедуралары үтәмичә генә контрактлар төзү, төзегән контрактларның шартларын нигезсез үзгәртү, продукция китерү һәм хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты һәм срокларының контракт таләпләренә туры килмәве.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы (670,4 мең сум), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (149,3 мең сум) тарафыннан сатып-алулар үткәрмичә генә товар һәм хезмәт күрсәтүгә килешүләр төзелгән.

Балык Бистәсе муниципаль районында заказ урнаштыру тәртибен үтәмичә генә гомуми күләме 1 161,5 мең сумга бюджет чараларын күчерү факты ачыкланды.

Яңа Чишмә муниципаль районында, дәүләт (муниципаль) сатып-алулары турында законнарын бозып, балалар мәйданчыклары өчен җиһазлар китерүгә 4 муниципаль контракт төзегән чакта котировка гаризаларында гомуми күләме 1 503,5 мең сумга товар сыйфатына таләпләр юк. Нәтиҗәдә, законны бозып, сертификация үтмәгән җиһаз китерелгән һәм урнаштырылган. Кайбер очракларда төзелгән муниципаль контрактлар шартлары һәм шуннан соң балаларга гомуми белем бирү учреждениеләренә

туклану продуктларын китерү (4 763,6 мең сумга) аукцион документларына туры килми.

**Дәүләт һәм муниципаль милек, җир ресурслары белән идарә нәтиҗәлелеген** тикшерү тарафыннан дәүләт (муниципаль) милекне аренда килешүе төземичә, аренда түләвен киметелгән ставкалар буенчабирү; милекне түләүсез куллануга нигезсез бирү; дәүләт (муниципаль) милек объектларын, җир участокларын базар бәясеннән сизелерлек дәрәҗәдә кимрәк бәягә сату фактлары ачыклана.

Шулай, Яшел Үзән муниципаль районында Идел елгасы ярында гомуми мәйданы 1,6 га җир кишәрлеге 509,6 мең сумга, ягъни бер сутыйга 3,2 мең сум бәя белән тормышка ашырылган. Шул ук вакытта шундый ук кишәрлекләрнең базар бәясе бер сутый өчен 100 мең сумга җитә.

Лаеш муниципаль районында җирләрне сатып-алулар уткәрмичә, минималь бәя буенча арендага бирү һәм тормышка ашыру фактлары ачыкланды. Районның башкарма комитеты тарафыннан сатып-алу үткәрмичәГабишево бистәсендәге 2,4 га җир сууткәргечне реконструкцияләү шарты белән шәхси затка бирелгән (аренда түләве елына 6,3 мең сум). Шуннан соң әлеге кишәрлекне 22 өлешкә бүлү үткәрелгән һәм хокуклар башка затларга күчерелгән. Сууткәргечне реконструкцияләү буенча шарт үтәлмәгән. Әлеге җирнең базар бәясе 26,4 млн. сум тәшкил итә.

**Социаль-мәдәни өлкә объектларын, күпфатирлы торак йортларны** капиталь ремонтлау үткәрүгә юнәлдерелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү барышында Хисап палатасы тарафыннан шактый бозулар ачыклана. Чынлыкта башкарылмаган эшләр өчен түләү Казан шәһәре мәгариф учреждениеләренең кайберләрендә ремонт үткәргәндә (8 416,1 мең сум), Мәскәү һәм Идел буе районнарында (матди зыян күләме 1 500 мең сум тәшкил итте), Яшел Үзән (703,9 мең сум), Арча (208,8 мең сум) муниципаль районнарында күпфатирлы торак йортларны ремонтлаган чакта урын алган.

Казан шәһәренең социаль өлкә объектларында капиталь ремонтлау үткәрүне тикшерү барышында ачыкланган эш күләмен арттыру фактлары буенча **җинаять эше ачылды**.



2012 елда Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе белән үзара хезмәттәшлек итү киңәйтелде. Хисап палатасы белгечләре Идарә үткәргән 7 комплекслы тикшерү чараларында катнашты.

Коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләренең һөнәри дәрәҗәсе үстерә максатында апрельдә «Финанс-бюджет өлкәсендә коррупциягә каршы тикшерү чараларын оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре» семинары үткәрелде.

Ревизия, финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча тренинг элементларын кушып, лекцияләр циклы белән икътисадый фәннәр докторы, Дәүләт аудиты югары мәктәбе профессоры З.Ә.Салихов чыгыш ясады.





Семинар барышында региональ һәм муниципаль дәрәҗәдә коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру, муниципаль дәрәҗәдә финанс-бюджет өлкәсендә коррупция билгесен ачыклау, коррупциягә каршы тикшерүе чараларын оештыру һәм үткәрү һәм финанс тикшерүе органнарында коррупцияне кисәтү мәсьәләләре каралды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы хезмәткәрләре һәм муниципаль тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре белән берлектә семинарда Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе, Татарстан Республикасында Финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең

территориаль идарәсе, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты вәкилләре катнашты.

Шулай ук Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы вәкилләре катнашында Хисап палатасы хезмәткәрләре өчен коррупция билгеләренә ия бозуларны ачыклау, квалификацияләү һәм тикшерү чаралары материалларында чагылдыру мәсьәләләре буенча семинар үткәрелде.

Хисап палатасында коррупцион хокук бозуларны кисәтү буенча һәрдаим эш алып барыла.

Тикшерү чаралары үткәргән вакытта бер үк объектта үткәрелгән тикшерү чараларында бер үк инспекторларның күп мәртәбә катнашуын кисәтү максатында инспекторлар составын системалы ротацияләү үткәрелде. Тикшерү чараларын үткәрү буенча эш төркемен төзү интереслар конфликтын булдырмау ихтыяҗын истә тотып тормышка ашырылды.

«Дәүләт хезмәткәренең коррупцион хокук бозулар ясауга тайпылу максатында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибе», Хисап палатасы аппараты дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан башка төр түләүле эш башкару турында хәбәр итү тәртибе расланды.

Хисап палатасы тарафыннан төзелгән килешүләр һәм дәүләт контрактларын үтәүне тикшерү, аларны үтәмәү яисә тиешле дәрәҗәдә башкармау фактлары турында үз вакытында хәбәр итү буенча йөкләмәләр, шулай ук Хисап палатасы тарафыннан төзелгән килешүләр һәм дәүләт контрактлары буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә башкармау фактлары буенча тиешле претензия-иск эшләрен оештыру һәм үткәрү буенча йөкләмәләр бирелгән җаваплы затлар билгеләнде.

Хисап палатасында Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм интереслар конфликтын көйләү буенча комиссия төзелде. Хисап елында Комиссиянең 5 утырышы үткәрелде.

Интереслар конфликтын булдырмау һәм җайлаштыру максатында Хисап палатасы инспекторлар составы тарафыннан коррупциягә каршы

законнар таләбен истә тоткан хәлдә тикшерү чаралары үткәргәндә «Тикшерү чаралары үткәргәндә Татарстан Республикасы Хисап палатасы хезмәткәрләре тәртибе кагыйдәләренең кыска исемлеге» эшләнде һәм расланды.

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә һәм интереслар конфликтын көйләүгә таләпләрне үтәү буенча Комиссия эшчәнлеге турында мәгълүмат Хисап палатасының рәсим сайтында һәрдаим урнаштырыла.

## Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү

2012 елда Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары ассоциациясе (АКСОР) белән үзара хезмәттәшлек һәм тәэсир итешүне үстерү буенча эш дәвам итте.



Декабрьдә Казанда Россия Федерациясе Хисап палатасы Коллегиясе һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы Коллегиясенең 2013 елда Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге универсиаданы оештыру, әзерләү һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән бюджет чаралары чыгымнарын тикшерү нәтиҗәләре буенча уртак утырышы узды. Әлеге юнәлеш буенча бюджет чараларын куллануны тикшерү буенча уртак эш 2013 елда да дәвам итәчәк.

Шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы белән берлектә Россия Федерациясе гражданнарына 2010-2012 еллар аралыгында бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыруга юлланган дәүләт чараларын куллану нәтиҗәлелегенә аудит үткәрелде.

2012 елның июнендә Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары ассоциациясе Президиумының Уфа шәһәрендә узган утырышында Россия

тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең (АКСОР) Идел буе федераль округындагы бүлекчәсе Рәисе А.И.Демидов «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» федераль закон нигезендә Идел буе федераль округында муниципаль тикшерү-хисап органнары төзү барышы турында доклад белән чыгыш ясады.




Ассоциация Президиумы Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеген комплекслы анализлау нәтиҗәләрен раслады. Татарстан Республикасы Хисап палатасы, 2007 елда беренчеләрдән булып сертификацияләү процедурасын узып, элек бирелгән эшчәнлегенең ил дәүләт финанс тикшерүе стандартларына һәм Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары принципларына туры килү таныклыгын раслады. Яңа бишьеллык вакытка туры килү сертификаты бирелде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы вәкилләре Россия тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең XIX һәм XX Конференцияләрендә, дәүләт финанс тикшерүен камилләштерү мәсьәләләренә багышланган берничә фәнни-гамәли конференциядә һәм түгәрәк өстәлдә катнашты.

Россия тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең «Россиянең иң яхшы финанс тикшерүчесе» исеменә ел саен үткәрелә торган бәйгесе нәтиҗәләре буенча Хисап палатасы аудиторы И.А.Мөбәрәков II дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләнде.

2012 елның июнендә Хисап палатасы командасы Башкортстан Республикасында узган Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары арасында бадминтон буенча III Бөтенроссия чемпионатында призер булды.

Хисап палатасы Россия тикшерү-хисап органнары ассоциациясе эшчәнлеге кысаларында үткәрелә торган фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә актив катнаша. 2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эш төркеме тарафыннан «Тикшерү-хисап органында тикшерү чараларының сыйфаты белән идарә итү» финанс тикшерүенең типовой стандарты эшләнде.

Хисап палатасы Россия тикшерү-хисап органнары ассоциациясе эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырылучы Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнарының дәүләт мәгълүмати-аналитик системасын (ТХО ДМАС) төзү буенча проектта катнаша. Хисап палатасы вәкилләре ТХО ДМАС Советы составына һәм эксперт төркеменә керә.

2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Саха (Якутия) Республикасы Хисап палатасы арасында хезмәттәшлек итү турында Килешү төзелде. Килешү кысаларында тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чаралары турында мәгълүмат, шулай ук дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүе өлкәсендәге норматив, методик һәм оештыру документлары белән алмашу каралган.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды – дәүләт корпорациясе белән хезмәттәшлек итү турында Килешүгә кул куелды.

Килешү предметы булып Татарстан Республикасына күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүгә һәм гражданнарны авария хәлендәге торак фондтан күчерүгә Фонд тарафыннан финанс ярдәме чараларын куллануның, Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан әлеге чараларны куллануның законлылыгы һәм нәтиҗәлелеге мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү тора.

Шулай ук Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсе арасында килешүгә кул куелды. Әлеге Килешүнең предметы булып хезмәттәшлек һәм үзара тәэсир итешү тәртибен урнаштыру тора, шулай ук тикшерү эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат белән алмашө, уртак тикшерүләр үткәрү, бер якның аерым белгечләре һәм экспертларының икенче як үткәргән тикшерү чараларында катнашуы күздә тотыла.

2012 елда Хисап палатасы вәкилләре АКСОР Конференциясендә (Мәскәү, 2012 елның 17 декабре), «Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге һәм энергияне саклау» Халыкара симпозиумында (Казан, 2012 елның 7 декабре) докладлар белән чыгыш ясадылар, квалификация күтәрү программалары кысаларында Россия Федерациясе Президенты каршындагы

Россия дәүләт хезмәте академиясе, ХП ФТИның Идел буе федераль округындагы филиалы, Казан (Идел буе) федераль университеты, Татарстан Республикасы Прокуратурасы оештырган семинарларны үткәрделәр

## Муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү

Хисап елында Хисап палатасы муниципаль финанс контроленең нәтиҗәлелеген күтәрү, аны тагын да камилләштерү, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшен дәвам итте.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары вәкилләре Россия муниципаль тикшерү-хисап органнары Союзының XI конференциясендә катнашты.



2012 елда Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советының 2 утырышы үткәрелде. 2012 елның декабрендә үткән утырышта муниципаль тикшерү-хисап органнары тарафыннан тормышка ашырыла торган тикшерүнең өстенлекле юнәлешләре билгеләнде, Татарстан Республикасы Хисап палатасы социаль өлкә, мәгариф һәм мәдәният тармакларының бюджет учреждениеләрендә үткәргән тикшерү чаралары үрнәгендә энергетик ресурсларны кулланганда бюджет чараларын тотуның нәтиҗәлелегенә муниципаль дәрәҗәдә аудит үткәрү мәсьәләләре каралды.

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 6-ФЗ номерлы федераль законның гамәлгә керүенә бәйле рәвештә Хисап палатасы һәм муниципаль тикшерү-хисап органнары белән берлектә тышкы муниципаль финанс тикшерүен тормышка ашыру мәсьәләләрен көйләүче норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча эш башкарылды. Хисап палатасы инициативасы буенча «Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Аның буенча муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы Рәисе муниципаль вазыйфа башкара. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 30 июлендә кабул ителгән 643 номерлы карары белән муниципаль тикшерү-хисап органнары җитәкчеләренең хезмәт хакы күләме билгеләнде.

Югары һөнәри дәрәҗәне тәэмин итү максатында муниципаль тикшерү-хисап органнары җитәкчеләрен эшкә алу һәм эштән азат итү Татарстан Республикасы Президенты Аппараты һәм Хисап палатасы Рәисе белән килешеп тормышка ашырыла.

Совет эше кысаларында ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлеген мониторинглау башкарыла.

2012 елда республиканың муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары тарафыннан 756 тикшерү-ревизия чарасы үткәрелде. Тикшерү вакытында 2018 объект колачланды.

**Муниципаль тикшерү-хисап органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерү-ревизия чаралары динамикасы**




Тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләр бюджетларына 404 млн. сумлык чара күрелде һәм торгызылды.

Муниципаль тикшерү-хисап органнары җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлекләр бюджеты чаралары хисабына чыгымнарны күздә тотучы һәм аны төзүгә һәм башкаруга тәэсир итүче норматив-хокукый актлары проектларына финанс экспертизасы үткәрә. 2012 елда муниципаль

тикшерү-хисап органнары тарафыннан 1113 экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде, 972 эксперт бәяләмәсе әзерләнде.

**Муниципаль тикшерү-хисап органнары тарафыннан үткәрелгән экспертиза-аналитика чаралары динамикасы**




Муниципаль тикшерү-хисап органнарына оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати, шул исәптән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелек аудитын оештыру һәм үткәрү буенча, ярдәм күрсәтелә. Совет эшчәнлеге турында мәгълүмат, норматив һәм методик документлар, квалификация күтәрү курслары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советының рәсми сайтында (http://www.ksort.ru) урнаштырыла.

## Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек итү

2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасының эшчәнлеге Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы кысаларында дәвам итте.

Республика территориясендә финанс тикшерүе органнарының үзара тәэсир итешүе Тикшерү чараларының җыелма планы нигезендә тормышка ашырылды.

Финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү-профилактикалау максатында республика министрлыкларына, ведомстволарына һәм муниципаль берәмлекләренә ел саен бозуларны һәм кимчелекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе барышында ачыклана торган бозулар һәм кимчелекләр Классификаторы юллана.



2012 елда ведомство эчендә финанс тикшерүен үстерү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының эчке аудит хезмәте җитәкчеләре 2012 елның 27 июнендә узган Совет утырышында катнашты.

Совет эшчәнлеге кысаларында бюджет өлкәсендә финанс дисциплинасын ныгытуга юнәлдерелгән методик документлар әзерләнде:

- «Бюджет чаралары белән төп идарә итүчене эчке тикшерүнең коррупция күренешләрен профилактикалауга юнәлдерелгән системасын оештыру буенча методик киңәшләр»;
- «Бюджет чараларын, дәүләт (муниципаль) милекне кулланганда коррупция куркынычын ачыклау буенча методик киңәшләр».

Әлеге документлар республика министрлыкларына, ведомстволарына һәм муниципаль берәмлекләренә җибәрелде.

Хисап палатасы, Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, Финанс-бюджет күзәтчелеге федераль хезмәтенең территориаль идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ачыкланган бюджет законнарын бозулар буенча мәгълүмат квартал саен гомумиләштерелде.

Хисап палатасы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ә.Ә.Сәфәров җитәкчелек иткән Татарстан Республикасы **икътисадында акчаларның тискәре әйләнешен кыскарту буенча тәкъдимнәр эшләү буенча эш** төркемендә катнаша. Төркем эшчәнлеге кысаларында законнан тыш финанс схемаларын кулланучы һәм фирмаларны

теркәү буенча хезмәт күрсәтә торган юридик затлар исемлеге әзерләнде; шикле фирмаларны күп итеп теркәү урыннары билгеләнде; тикшерү чаралар үткәргән чакта «бер көнлек фирмалар» катнашы белән акчаларны законсыз рәвештә кулга алу итүгә кагылышлы финанс операцияләрен ачыклауга аерым игътибар бирелә.

Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән нәтиҗәле мәгълүмати һәм документацион хезмәттәшлек итү өчен шартлар тудыру максатында, Хисап палатасы «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» электрон документ әйләнеше бердәм ведомствоара системасына кертелде.

## Эшчәнлектә хәбәрдарлык

Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасының Коллегия, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү Советы һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары һәрдаим массакүләм матбугат чараларында, шул исәптән федераль басмаларда яктыртылып торды.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.ru), Россия Тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең «Россия Хисап палаталары» сайтында (http://www.ach-fci.ru) һәм Россия Тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең «АКСОР хәбәрчесе» («Вестник АКСОР») журналында урнаштырылды.

«АКСОР хәбәрчесе» журналында (№2, 2012) Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидовның «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләргә бюджет чараларын куллануга нәтиҗәлелек аудиты» мәкаләсе һәм Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы эшчәнлеге турында күзәтүле мәкаләсе басылып чыкты.

Татарстан Республикасы Хисап палатасының рәсми сайтыннан алынган мәгълүмат федераль мәгълүмат агентлыклары (РИА-Новости, Интерфакс-Поволжье, Прайм-ТАСС, ИТАР-ТАСС, РЕГНУМ һ.б.) тарафыннан кулланылды.

2012 елда Хисап палатасы сайтына 20 624 (2011 елда – 17 135, 2010 елда – 12 790) мәртәбә керү теркәлгән.

2012 елда массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет-басмалар, журналлар, газеталар һәм телевидениедә) Хисап палатасы эшчәнлеге 211 материалда һәм телесюжетта тәкъдим ителде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге хроникасы квартал саен Татарстан Республикасы Хисап палатасының мәгълүмати бюллетенендa басылды. Хисап палатасы бюллетеньнары Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.